| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.10.2022 г. Казань № 2805

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 20.07.2017 № 1574 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә б о е р а м:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 20.07.2017 № 1574 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 03.06.2019 № 1130 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

пункт 1 икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Министрлык) эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән Министрлыкта төзелгән беренчел

профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә катнашудан тыш, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.»;

пункт 3 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуы очрагында Граждан хезмәткәренең турыдан туры җитәкчесе тарафыннан алдан алынган фикер белән хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге булу (булмау) турында гариза граждан хезмәткәре тарафыннан коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - җаваплы затка) түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашуга кадәр тапшырыла.

Гаризага коммерциячел булмаган оешманың гамәлгә кую документының күчермәсе теркәлә, аның идарәсендә граждан хезмәткәре түләүсез нигездә катнашуны күздә тота.».

Тәртипкә кушымта № 1 яңа редакциядә бәян итәргә (кушып бирелә).

Министр М.Н.Садыков

Г.Р.Накипова
(843) 231-79-15

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 20.07.2017 № 1574 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 21.10.2022 № 2805 боерыгы редакциясендә)
Кушымта № 1

Форма

Татарстан Республикасы
сәламәтлек саклау министрына

______________________________________________
(фамилия-исем)

______________________________________________
(гариза бирүче дәүләт граждан хезмәткәренең

______________________________________________
фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта),

______________________________________________
вазифасы)

Гариза
Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт бирү турында

Түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт бирүегезне сорыйм: ______________________________________________________
(коммерциячел булмаган оешманың тулы исеме,
______________________________________________________________________________,
юридик адресы, коммерциячел булмаган оешманың ИНН)
_____________________________________________________________________________

Түбәндәге сыйфатта_____________________________________________________
(коммерциячел булмаган оешманың бердәнбер башкарма органы
______________________________________________________________________________.
яки коллегиаль идарә итү органы исеме)

Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу дәүләт граждан хезмәте үтүдән буш вакытта башкарылачак һәм граждан хезмәтендә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүгә яисә дәүләт мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китермәячәк.

Кушымта. коммерциячел булмаган оешманың гамәлгә кую документының күчермәсе

| | | |
|---|---|---|
| (гариза бирүче дәүләт граждан хезмәткәренең имзасы) | (исем-фамилиясе) | (дата) |

Дәүләт граждан хезмәткәренең дәүләт граждан хезмәткәре вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге булу (булмау) турында дәүләт граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе фикере:

| | | | |
|---|---|---|---|
| (гариза бирүче дәүләт граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесенең вазифасы) | (имза) | (исем-фамилия) | (дата) |